# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№3 14.11.2019

Илексаз авылында халык җыены нәтиҗәләре турында,

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы

Илексаз авыл җирлеге составына керүче

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45 номерлы Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә - "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында «Татарстан Республикасы законы проекты белән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200,00 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

- Мортыш Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;;

-Мортыш Баш авылында «Беларус 82.1» тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәте өчен түләү):

- Мортыш Баш авылында " Сабантуй» мәйданын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

- Мортыш Баш авылында урамнарны яктырту лампочкалары сатып алу.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 211 кеше, гражданнар җыенында катнашучылар саны 187 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 182 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы составына керүче Илексаз авыл җирлегенең Мортыш Баш авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Мортыш Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, вакытлы хәрби хезмәт үтүче 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2020 елда 200,00 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә риза:

- Мортыш Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

-Мортыш Баш авылында «Беларус 82.1» тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

- Мортыш Баш авылында " Сабантуй» мәйданын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

- Мортыш Баш авылында кабул ителгән урамнарны яктырту лампочкалары сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә һәм махсус мәгълүмати стендларда урнаштырылган: Мортыш Баш авылы, Мәктәп урамы, 4а йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче

Илексаз авыл җирлеге башлыгы Ф. М. Гыйльфанов

Республика Татарстан Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Муниципальное образование Сармановский муниципальный район ОГРН 1021601313183 Совет Иляксазского сельского поселения Илексаз авыл жирлеге Советы ИНН 1636001354